ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) тиешле хисап (салым) чоры өчен керемнең кимендә 90 процентын Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының 62 «Компьютер программаларын әзерләү, шушы өлкәдә консультация хезмәтләре күрсәтү һәм башка хезмәт күрсәтүләр» һәм 63 «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан алынган керем тәшкил иткән очракта, федераль башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы органы мәгълүматы буенча халык саны 7 мең кешегә кадәр җиткән шәһәрләрдә тору урыннары (яшәү урыннары) булган салым түләүчеләр өчен.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ статья өстәргә:

**«$1^{1}$ статья**

Федераль башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы органы мәгълүматы буенча халык саны 7 мең кешегә кадәр җиткән шәһәрләрдә тору урыннары (яшәү урыннары) булган салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы һәм салым салу объекты буларак керемнәрне билгеләгән салым түләүчеләр өчен, тиешле хисап (салым) чоры өчен керемнең кимендә 90 процентын Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының 62 «Компьютер программаларын әзерләү, шушы өлкәдә консультация хезмәтләре күрсәтү һәм башка хезмәт күрсәтүләр» һәм 63 «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә эшчәнлек» кодларына туры килә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан алынган керем тәшкил иткән очракта, салым ставкасын 1 процент күләмендә билгеләргә.»;

3) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) 2023 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктының һәм $1^{1}$ статьясының.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 26 февраль
№ 3-ТРЗ